ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.05.2019 № 777

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2018-2020 елларга Алабуга муниципаль районы территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, халыкның куркынычсызлыгын тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында»гы 2017 нче елның 20 нче декабрендәге 1604 нче санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2014 нче елның 9 нчы июлендәге 765 нче санлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2018-2020 елларга Алабуга муниципаль районы территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, халыкның куркынычсызлыгын тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында»гы 2017 нче елның 20 нче декабрендәге 1604 нче санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2018-2021 елларга Алабуга муниципаль районы территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, халыкның куркынычсызлыгын тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында».

2. «2018-2021 елларга Алабуга муниципаль районы территориясендә террорчылык һәм экстремизмны профилактикалау, халыкның куркынычсызлыгын тәэмин итү» муниципаль программасын яңа редакциядә расларга (алга таба – Программа).

3. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Э. И. Садыйкова) агымдагы финанслау хисабына муниципаль программа чараларын финанслауны күздә тотуны тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.С. Хәйруллин